КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 20 июнь г.Казань № 590

2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында яшь геологларның VIII республика ачык кыр олимпиадасын үткәрү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасын уздыру турында” 2014 ел, 30 май, 365 нче карары белән расланган яшь геологларның ачык кыр олимпиадасын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында яшь геологларның VII республика ачык кыр олимпиадасын 2022 елның 11 июленнән 17 июленә кадәр “Кояшлы” балалар сәламәтләндерү лагере базасында уздырырга.

2. 2022 елда яшь геологларның VIII республика ачык кыр олимпиадасына әзерләү һәм аны уздыру буенча чараларның беркетелгән планын (алга таба - план) расларга.

3. Яшь геологларның VIII республика ачык кыр олимпиадасын (алга таба - олимпиада) оештыру комитетына:

план чараларының үтәлешен координацияләргә;

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2020 елның 30 июнендәге 16 номерлы карары белән расланган «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралу шартларында балалар һәм яшьләр өчен мәгариф оешмаларының һәм социаль инфраструктураның башка объектларының эшчәнлегенә, эчтәлегенә һәм эшен оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 3.1/2.4.3598-20 санитар-эпидемиологик кагыйдәләр, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының

2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары белән расланган «Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.4.3648-20 санитар-эпидемиологик кагыйдәләр, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2020 елның 27 октябрендәге 32 номерлы карары белән расланган «Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» СанПиН 2.3/2.4.3590-20 санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормалар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карары нигезендә олимпиада үткәрүне тәэмин итәргә;

2022 елда олимпиада әзерләү һәм уздыру буенча чараларның берләштерелгән смета исәбен расларга.

4. В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте, «Нефтеконсорциум» ябык акционерлык җәмгыяте, кече нефть компанияләре 2022 елда яшь геологларның мәктәп командаларын әзерләүдә һәм яшь геологларның VIII Республика ачык кыр олимпиадасын уздыруда һәрьяклап ярдәм күрсәтү турында тәкъдимнәрне кушымта нигезендә кабул итәргә.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Яшь геологларның VIII республика ачык кыр олимпиадасын үткәрү турында нигезләмәне расларга;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 05 март, 158 нче карары белән расланган «2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасының «2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр һәм яшьләр ялын оештыру» ярдәмче программасы кысаларында 2022 елга Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчалар исәбеннән олимпиаданы оештыру һәм уздыру чыгымнарын финанслауны тәэмин итәргә;

В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте, «Нефтеконсорциум» ябык акционерлык җәмгыяте һәм Татарстан Республикасының кече нефть компанияләре белән олимпиада уздыру мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек оештырырга.

6. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, шулай ук олимпиада уздыруда катнашучы башка органнарга һәм оешмаларга план чараларын билгеләнгән вакытта үтәүне тәэмин итәргә.

7. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына олимпиада уздыруның массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

8. Тәкъдим итәргә:

«Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең геология һәм нефть-газ технологияләре институтына олимпиадага фәнни-методик җитәкчелек итәргә;

Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетына:

олимпиаданы әзерләүдә һәм уздыруда оештыру комитетына ярдәм итәргә;

уздыру объектларында һәм олимпиадада катнашучыларның яшәү урыннарында

янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итәргә;

олимпиада уздыру объектлары һәм олимпиадада катнашучыларның яшәү урыннары әзерлеген тикшереп торуны тәэмин итәргә.

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасын үткәрү турында» 2014 ел, 30 май, 365 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 май, 384 нче; 2015 ел, 12 ноябрь, 851 нче; 2016 ел, 22 июнь, 427 нче; 2017 ел, 24 апрель, 242 нче, 2018 ел, 28 май, 402 нче, 2021 ел, 25 июнь, 499 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымтада бирелә).

10. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 20 июнь, 590 нчы
карары белән расланды

2022 елда яшь геологларның VIII республика ачык кыр олимпиадасына әзерләү һәм аны уздыру буенча чаралар планы

| Т/с | Чараның исеме | Җаваплы башкаручылар | Ярдәмче башкаручылар | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | «Кояшлы» балаларны савыктыру лагере базасында стационар лагерьлар эшенә куела торган санитария законнары таләпләрен исәпкә алып һәм шәһәр читендәге лагерьның санитария законнары таләпләренә туры килүен билгели торган санитар-эпидемиологик нәтиҗә алу («Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.4.3648-20 санитария кагыйдәләре һ.б.) «Кояшлы» балалар савыктыру лагеренең радиотапшыруларының бердәм системасын оештыру эшләрен башкару | Яшь геологларның VIII республика ачык кыр олимпиадасын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты (алга таба - оештыру комитеты), В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте (килешү буенча) | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) | 11.07.2022 кадәр |
| 2. | Түбәндәгеләрне раслау:<br>Яшь геологларның VIII республика ачык кыр олимпиадасын үткәрү турында нигезләмә;<br>яшь геологларның VIII республика ачык кыр олимпиадасын (алга таба - олимпиада) | оештыру комитеты | югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү | 20.06.2022 кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | оештыру комитеты составы:<br>суд коллегиясе составы | | буенча) | |
| 3. | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе каршындагы Яшь геолог мәктәбенең уку процессын, олимпиадада катнашуга гариза биргән мәгариф оешмалары базасында түгәрәкләр оештыру | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) | оештыру комитеты | ел дәвамында |
| 4. | Ярышларның кыр маршрутларын, планлаштырылган стоянкалар урыннарын эшләү һәм оештыру, олимпиада башланганчы 30 көннән дә соңга калмыйча аларны кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе белән килештерү | оештыру комитеты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) | 20.06.2022 |
| 5. | «Кояшлы» балалар сәламәтләндерү лагере базасында һәм олимпиада уздырганда билгеләнгән кыр маршрутлары, планлаштырылган стоянкалар нигезендә дератизацион (лагерь тирәсендә 200 метр барьер, лагерь территориясе) һәм акарицид эшкәртү (лагерь тирәсендә 50 метр барьер, лагерьның яшел территориясе) уздыруны тәэмин итү:<br>дератизация - олимпиада башланырга 30 көн кала Әлмәт, Зәй, Лениногорск муниципаль | оештыру комитеты, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) | 20.06.2022 кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | районнарында «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе филиалы көчләре белән берлектә нәтиҗәлелекне бәяләү үткәрелеп; акарицидлы - олимпиада башланырга 20 көн кала эшкәртүнең нәтиҗәлелеген икеләтә бәяләү (акарицид эшкәртүдән соң 3 - 5 көн һәм 15 - 20 көн узгач) «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Әлмәт, Зәй, Лениногорск муниципаль районнарында филиаллары көчләре белән | | | |
| 6. | Алдан (эшкә урнашканда) һәм әледән-әле медицина тикшерүләрен үтүгә кагылышлы таләпләргә (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 213 статьясындагы дүртенче өлешендә каралган хезмәткәрләргә мәҗбүри алдан һәм әледән-әле медицина тикшерүләрен үткәрү тәртибен, зарарлы һәм (яки) куркыныч җитештерү факторлары булган эшләрне, шулай ук мәҗбүри алдан һәм әледән-әле медицина тикшерүләре үткәрелә торган эшләрне башкаруга карата медицина күрсәтмәләре исемлеген раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 29н номерлы | оештыру комитеты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) | | 20.06.2022 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | боерыгы) туры килә торган, һөнәри гигиена әзерлеге һәм аттестациясе, вакцинациясе, медицина тикшеренүләре һәм лаборатория тикшеренүләре нәтиҗәләре күрсәтелгән, прививкалар, авырган йогышлы авырулары турында, эшкә рөхсәт ителгән һөнәри гигиена әзерлеге һәм аттестация узу турында мәгълүматлар бирелгән шәхси медицина кенәгәсе булган хезмәткәрләрне җәлеп итеп, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесеннән волонтерлар һәм вожатыйлар сайлау һәм әзерләү.<br>Олимпиада башлану алдыннан персоналында яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) булу-булмауга тикшерү оештыру (тикшерү, Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән диагностика препаратларын һәм тест-системаларын кулланып, яңа коронавирус йогышлы авыруын тудыручының генетик материалын яки антигеннарын билгели торган ысулларның теләсә ниндие белән гамәлгә ашырыла һәм тикшерү нәтиҗәләре эшкә чыгу көненә кадәр кимендә өч календарь көн алдан бирелә) | | | |
| 7. | Минераллар, тау токымнары, палеонтология коллекцияләре, кисемнщр төзү буенча уку | оештыру комитеты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» | | 20.06.2022 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | геологик карталары әзерләү | югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) | | |
| 8. | Олимпиада үткәрү өчен кирәкле җиһазлар һәм аппаратура белән тәэмин итү | оештыру комитеты | В.Д.Шашин исемен-дәге «Татнефть» гава-ми акционерлык җәм-гыяте (килешү буенча) | 20.06.2022 |
| 9. | Гамәлдәге санитар-эпидемиологик таләпләр нигезендә олимпиада үткәрү урыннарында катнашучыларны кабул итү, урнаштыру, яшәү, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуны профилактикалау.<br>Профилактика һәм дезинфекция чараларын үткәрү, яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуны кисәтү чаралары буенча санитария законнары таләпләрен исәпкә алып, олимпиадада катнашучы-ларның туклануын оештыру, шул исәптән олимпиада башлану алдыннан «Кояшлы» балаларны савыктыру лагереның азык-төлек цехы хезмәткәрләрен эчәк инфекция-ләренең норо-, рота- һәм башка вирус тудыручыларның булу-булмавына тикшерү үткәрү (эшкә чыгу көненә кадәр кимендә өч календарь көн алдан) | оештыру комитеты, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) | Татарстан Республика-сының Әлмәт муни-ципаль районы баш-карма комитеты (киле-шү буенча) | 11.07.2022 – 17.07.2022 |
| 10. | Олимпиада уздыруны IT-инфраструктура объектлары белән мәгълүмати-технологик тәэмин итү, шул исәптән: олимпиада штабы | В.Д.Шашин исемендәге «Тат-нефть» гавами акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) | оештыру комитеты | 11.07.2022 – 17.07.2022 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | оештыру, оештыру техникасы һәм компьютерлар белән комплектлау | | | |
| 11. | Олимпиаданың мәдәни һәм спорт программаларын оештыру, шул исәптән: олимпиаданы ачу һәм ябу сценарийларын эшләү һәм аларны гамәлгә ашыру; олимпиада үткәрү көннәрендә мәдәни-ял итү программасын гамәлгә ашыру | оештыру комитеты | | 11.07.2022 – 17.07.2022 |
| 12. | Олимпиада уздырыла торган урыннарда җәмәгать тәртибен һәм куркынычсызлыкны тәэмин итүдә оештыручыга ярдәм күрсәтү | оештыру комитеты, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) | 11.07.2022 – 17.07.2022 |
| 13. | Катнашучыларның яшәү, тукландыру һәм олимпиада уздыру урыннарында санитар-эпидемиологик таләпләрнең үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуны профилактикалау | оештыру комитеты | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) | 11.07.2022 – 17.07.2022 |
| 14. | Олимпиаданы әзерләү һәм үткәрү чорында оештыручыга санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итүдә булышлык күрсәтү | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча) | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) | әзерлек чорында - 17.07.2022 кадәр |
| 15. | Олимпиадада катнашучылар яшәгән урыннарда янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итү | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) | 11.07.2022 – 17.07.2022 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 16. | Олимпиада уздыруга медицина ярдәме күрсәтү, шул исәптән:<br>олимпиада үткәрелгән урында медпункт оештыру;<br>олимпиада уздыру урыннарында шартнамә нигезендә ашыгыч медицина ярдәме бригадасының кизү торуын оештыру | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) | 11.07.2022 – 17.07.2022 |
| 17. | «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралу шартларында балалар һәм яшьләр өчен мәгариф оешмаларының һәм социаль инфраструктураның башка объектларының эшчәнлегенә, эчтәлегенә һәм эшен оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 3.1/2.4.3598-20 санитария таләпләрендә бәян ителгән йөрү шартлары нигезендә катнашучыларның олимпиада уздыру урынына барып җитүен һәм кире кайтуын тәэмин итү (2022 елның 21 мартына үзгәрешләр белән) | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | оештыру комитеты | 11.07.2022 – 17.07.2022 |
| 18. | Республика массакүләм мәгълүмат чараларында олимпиада уздыруны яктыртуны тәэмин итү | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) | оештыру комитеты | 11.07.2022 – 17.07.2022 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 20 июнь, 590 нчы
карарына кушымта

В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте, «Нефтеконсорциум» ябык акционерлык җәмгыяте, кече нефть компанияләре 2022 елда яшь геологларның мәктәп командаларын әзерләүдә һәм яшь геологларның VIII Республика ачык кыр олимпиадасын уздыруда һәрьяклап ярдәм күрсәтү турында тәкъдимнәре

| Т/с | Лицензия хуҗасы (җир асты байлыкларыннан файдаланучы) | Кертем суммасы, сум |
|---|---|---|
| 1. | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ | 12 300 000,0 |
| 2. | «ТатРИТЭКнефть» территориаль-җитештерү предприятиесе | 440 000,0 |
| 3. | «Татнефтеотдача» АҖ | 265 000,0 |
| 4. | «Кара Алтын» предприятиесе» ЯАҖ | 220 000,0 |
| 5. | «Татех» АҖ | 185 000,0 |
| 6. | «Татойлгаз» АҖ | 185 000,0 |
| 7. | «Шешмаойл» АҖ | 175 000,0 |
| 8. | «Татнефтепром-Зюзеевнефть» АҖ | 135 000,0 |
| 9. | «МНКТ» ҖЧҖ | 200 000,0 |
| 10. | «СМП-Нефтегаз» АҖ | 110 000,0 |
| 11. | «Алойл» ЯАҖ | 110 000,0 |
| 12. | «Татнефтепром» АҖ | 110 000,0 |
| 13. | «Охтинойл» ЯАҖ | 120 000,0 |
| 14. | «Троицкнефть» ЯАҖ | 105 000,0 |
| 15. | «Иделойл» АҖ | 90 000,0 |
| 16. | «Булгарнефть» АҖ | 60 000,0 |
| 17. | «НК-Геология» ҖЧҖ | 75 000,0 |
| 18. | «Геология» АҖ | 50 000,0 |
| 19. | «Трансойл» ҖЧҖ | 65 000,0 |
| 20. | «ГРИЦ» АҖ | 55 000,0 |
| 21. | «Геотех» АҖ | 40 000,0 |
| 22. | «Меллянефть» АҖ | 25 000,0 |
| 23. | «Кондурчанефть» АҖ | 25 000,0 |
| 24. | «Карбон-Ойл» ҖЧҖ | 30 000,0 |
| 25. | «Акмай» ААҖ | 5 000,0 |
| 26. | «МАКойл» АҖ | 5 000,0 |
| 27. | «Алабуганефть» АҖ | 5 000,0 |
| 28. | «Камаойл» ҖЧҖ | 10 000,0 |
| | Барлыгы | 15 200 000,0 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2014 ел, 30 май, 365 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 20 июнь, 590 нчы
карары редакциясендә)

Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасын
әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры, оештыру комитеты рәистәше |
| Маганов Наил Өлфәт улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры, оештыру комитеты рәистәше (килешү буенча) |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әфләтунов Ринат Рәкыйп улы | баш геолог - В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Бачков Альберт Петрович | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең нефть һәм газ ятмаларының геология идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Вәлиев Фәнис Хамат улы | «Нефтеконсорциум» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Гаврилов Евгений Владимирович | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Персонал белән эшләү идарәсенең корпоратив мәдәниятне һәм яшьләр сәясәтен үстерү бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Галиев Ренат Марат улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гатиятуллин Рамил Нәкыйп улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Татар геологик разведка идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Глазков Андрей Александрович | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Персонал белән эшләү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Закирова Минзалия Заһри кызы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары |
| Исламова Гөлнара Илдар кызы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» дәүләт автоном учреждениесе директоры |
| Мотыйгуллин Равил Хәйдәр улы | «Файдалы казылмалар запаслары буенча дәүләт комиссиясе» федераль бюджет учреждениесенең казан филиалы директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Мөхәммәдиев Рөстәм Нәбиулла улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең социаль үсеш буенча генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Мөхәммәтшин Ренат Нурислам улы | Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаменты башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Ногыманов Тимур Дмитриевич | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Нургалиев Данис Карл улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе проректоры, Геология һәм нефть-газ технологияләре институты директоры (килешү буенча) |
| Патяшина Марина Александровна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Садыйков Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Таюрский Дмитрий Альбертович | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Хәбибуллин Рафис Җәүдәт улы | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Шадриков Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры. |